ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2022 г. Заинск № 115

**2036 елга кадәр Зәй шәһәрен жылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында**

“Жылылык белән тәэмин итү турында” 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясендә жылылык белән тәэмин итүне оештыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2012 елның 08 августындагы 808 номерлы, «Жылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында» 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты

**карар бирә**:

1. 2036 елга кадәр Зәй шәһәрен жылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын кушымта нигезендә расларга.
2. “2036 елга кадәр Зәй шәһәрен жылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында” 2021 елның 30 июнендәге 83 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй шәһәрен жылылык белән тәэмин итү схемасын билгеләнгән тәртиптә Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз жаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **А.В. Чапков**

Ю.А. Сычева
7 10 27
О.В. Федоткина
3 37 37